**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкэ авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы №90-50 «27» ноябрь 2023ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкэ авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 104номерлы “Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында (20.08.2015 №130, 04.08.2017 №60-30, 09.10.2018 №118-54, 19.07.2019 №143-67, 05.11.2019 №152-70, 22.10.2020 №10,11.08.2021 №35-18 (карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Туйкә авыл җирлеге карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкэ авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 104номерлы “Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында (20.08.2015 №130, 04.08.2017 №60-30, 09.10.2018 №118-54, 19.07.2019 №143-67, 05.11.2019 №152-70, 22.10.2020 №10,11.08.2021 №35-18 карарлар редакциясендә)2 пунктның икенче пунктчасына түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) кадастр бәясенең 0,3 проценты;»

2. Әлеге карар «Маяк» район газетасында басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны район «Маяк " газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга:http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru. веб адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р. Закирова